2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авылы җирлеге Бишмунча авылында гражданнарның үзара салымын керту турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

20 ноябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата – аналарыннан, хатыны, балаларыннан) тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларга асфальт салу)?».

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Бишмунча, Совет урамы, 57а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бишмунча авыл җирлеге башлыгы М.Т.Мөбәрәкшин